РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА
ТОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Джалиля , д.19, с.Түйкә,
Азнакаевский район, 423302

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТУЙКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Җәлил ур., 19 нче йорт, Туйкә авылы,
Азнакай районы, 423302

Тел./факс(885592)-45089; E-mail: Toy.Azn@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь 2024ел

№6

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2024 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлегенең Туйкә торак пунктында Туйкә авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2 Билгеләү:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлегенең Туйкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге башкарма комитеты;

– гражданнар җыенын үткәрү вакыты-2024 елның 18 ноябрендә 10.00 сәгатьтән 11.30 сәгатькә кадәр;

– гражданнар җыенын уздыру урыны-Туйкә авылы, Гагарин ур., 4А йорт, Туйкә авылы мәдәният йорты залы;

3.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

-2024 елның 08 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түйкә авылы, Җәлил урамы,19 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Түйкә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Түйкә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2025елда Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы

студентлардан, гаилә әгъзалары мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гаиләләр, ирекле хезмәткәрләр, контракт буенча хәрби хезмәткәрләр Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә махсус хәрби операциядә катнашучылар дан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Туйкә торак пункты чикләрендәге торак пункт территориясен төзекләндерү(юлларны кардан чистарту, чүп үләннәреннән чистарту һәм чабу, Туйкә авылында эскәмияләр әзерләү ,сатып алу (килешү буенча эш өчен түләү) ;

- Туйкә торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (энергияне саклый торган яктырткычларны һәм урамнарны яктырту лампаларын алмаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү) ремонтлау" ;

- Туйкә торак пунктында Ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (куакларны кисү, экскаватор белән агач төпләрен тарттыру, гербицид сатып алу, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, үләнне чабу-килешү буенча түләү)

- Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә.;

Туйкә авылында коеларны төзекләндерү, аларга якын территорияне төзекләндерү, су белән тәэмин итү челтәрләренең өзеклекләрен бетерү ; эшләр өчен килешү буенча түләү) ;

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, һәм түбәндәге адреслар җуенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлили ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Камышлы-Күл, Ленин ур., тукталыш янында;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы-Елга ур., Сәйдәшев ур., № 19а йорт янында;

7. Әлеге карар игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Рәис Р.Р.Закирова